БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«01» 04 20___ ел № 139

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында**

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр эшчәнлеген булдыру һәм оештыру буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы һәм «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында» 2021 елның 15 мартындагы 45 номерлы Балтач район Советы карары нигезендә, Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Балтач муниципаль районының административ комиссиясен төзергә.
2. Расларга:

Балтач муниципаль районының административ комиссиясе составын (1 нче кушымта);

Балтач муниципаль районының административ комиссиясенең эш регламентын (2 нче кушымта).

3. Балтач муниципаль районының административ комиссиясе вәкаләтләре чоры әлеге административ комиссиянең беренче утырышыннан башлана һәм биш ел тәшкил итә.
4. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының административ комиссиясен төзү турында» 2011 елның 15 мартындагы 146 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары үз көчен югалткан дип танырга.
5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет - ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесенең
2021 елның 01.04
139 номерлы карары белән
расланган

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының административ комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Хәйретдинов А. Ф. | Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе - комиссия рәисе; |
| Галимуллин И. С. | Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары - комиссия рәисе урынбасары; |
| Муллахмәтов Ф. Ш. | Балтач муниципаль районы административ комиссиясенең җаваплы секретаре; |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Фатыхов Р. С. | Балтач район башкарма комитетының юридик бүлек башлыгы; |
| Газизуллин Ф. Ф. | Эчке эшләр министрлыгының Балтач муниципаль районы буенча бүлеге полиция начальнигы урынбасары; |
| Зәкиев В. М. | «Татмедиа ААЖ» филиалы «Хезмәт» газетасы редакциясе директоры – баш мөхәррире; |
| Маннапова Г. С. | «Кайтаваз телерадиокомпаниясе» МБУ җитәкчесе; |

2 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесенең
2021 елның 01.04
139 номерлы карары белән
расланган

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының административ комиссиясенең эш**
**РЕГЛАМЕНТЫ**

Әлеге Регламент Балтач муниципаль районының административ комиссиясенең (алга таба - Комиссия) эш тәртибен билгели.

Әлеге Регламент таләпләре административ Комиссия эше өчен мәҗбүри.

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Административ комиссия «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр эшчәнлеген булдыру һәм оештыру буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе карары белән төзелә.

1.2. Комиссия үз вәкаләтләрен Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы конституцияләре, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары, Балтач муниципаль районы Уставы, Балтач муниципаль районының төзекләндерү өлкәсендәге норматив-хокукый актлары һәм әлеге регламент нигезендә гамәлгә ашыра.

1.3. Комиссия Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында, Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексында каралган административ хокук бозулар турындагы эшләрне карау өчен төзелә торган даими эшләүче коллегиаль орган булып тора һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы чикләрендә эшли.

1.4. Комиссия бурычлары булып административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы һәм административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә һәр эшне һәрьяклап, тулы, объектив һәм вакытында карау, чыгарылган карарны үтәүне тәэмин итү, шулай ук административ хокук бозуларны кисәтү тора.

1.5. Комиссиянең вәкаләтләр чоры әлеге комиссиянең беренче утырышы көненнән башлана һәм Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе

вәкаләтләре вакытына билгеләнә. Күрсәтелгән вакыт узганнан соң, Комиссия яңа составтагы административ комиссиянең беренче утырышы көненә кадәр үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны дәвам итә.

1.6. Комиссия әгъзасының вәкаләтләре «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр эшчәнлеген булдыру һәм оештыру буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законында каралган очракларда вакытыннан алда туктатыла.

1.7. Балтач район башкарма комитеты Комиссия әгъзасының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында карар кабул ителгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча үз вәкаләтләрен вакытыннан алда туктаткан Комиссия әгъзасы урынына административ комиссиянең яңа әгъзасын билгеләп куярга тиеш.

1.8. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетына Комиссияне булдыру һәм аның эшчәнлеген оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенция Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә. Финанслау Балтач район башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

1.9. Административ комиссиянең герблы мөһере, үз исеме һәм район гербы сурәтләнгән бланклары бар.

1.10. Комиссияне булдыру һәм аның эшчәнлеген оештыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы, Балтач район башкарма комитеты контрольдә тота.

## 2. Административ комиссия эшен оештыру

2.1. Комиссия Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе карары белән раслана торган административ комиссиянең рәисеннән, рәис урынбасарыннан, җаваплы секретареннән һәм административ комиссия әгъзаларыннан тора.

2.2. Комиссия әгъзалары үз вәкаләтләрен «Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр эшчәнлеген булдыру һәм оештыру буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә гамәлгә ашыралар.

2.3. Административ комиссиянең персональ һәм санлы составы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан 5 кешедән дә ким булмаган санда билгеләнә һәм состав так санда булырга тиеш.

2.4. Комиссия составына даими штат нигезендә административ комиссиянең җаваплы секретаре керә. Комиссиянең башка әгъзалары административ комиссиядә, әлеге регламентның 2.5 пунктында каралган очраклардан тыш, иҗтимагый башлангычларда эшлиләр.

2.5. Балтач район башкарма комитеты карары буенча Комиссиянең башка әгъзалары үз вазыйфаларын даими рәвештә түләүле нигездә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты акчалары хисабына башкара алалар.

2.6. Комиссия рәисе административ комиссиянең рәисе урынбасары һәм җаваплы секретаре арасында вазыйфаларны бүлә, аларның функцияләрен Татарстан Республикасы законы белән бирелгән вәкаләтләр чикләрендә билгели.

2.7. Комиссия рәисе административ комиссия әгъзаларының, шулай ук административ комиссия рәисе урынбасарының һәм җаваплы секретаренең квалификациясен күтәрү эшен оештыра.

2.8. Комиссия килүчеләрне кабул итә. Килүчеләрне кабул итү тәртибе Комиссия рәисе күрсәтмәсе белән билгеләнә.

2.9. Комиссия адресына гражданнардан һәм юридик затлардан кергән шикаятьләр һәм мөрәҗәгатьләр гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда карала.

2.10. Комиссия үз эшен расланган еллык план буенча оештыра.

2.11. Административ хокук бозулар буенча эшләр административ комиссиядә саклана һәм, 2 ел узгач, Балтач район башкарма комитетының архив бүлегенә тапшырыла.

3. Административ комиссия утырышын чакыру һәм уздыру тәртибе

3.1. Административ хокук бозулар турындагы эшләрне Комиссия тарафыннан карап тикшерү Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

3.2. Административ хокук бозулар турындагы эшләр административ комиссия утырышларында карала.

3.3. Комиссия утырышлары айга ике тапкыр (айның икенче һәм дүртенче пәнҗешәмбесендә), Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 29.6 статьясы нигезендә административ хокук бозулар турындагы эшләрне карау вакытын үтәүне тәэмин итә торган вакыт аралыгы белән үткәрелә.

3.4. Административ комиссиянең җаваплы секретаре комиссия әгъзаларына административ комиссия утырышын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында административ комиссия утырышына кадәр кимендә 3 көн алдан хәбәр итә.

3.5. Административ комиссия утырышында катнашу мөмкин булмаган очракта, комиссия рәисе, рәисе урынбасары һәм әгъзалары бу хакта административ комиссиянең җаваплы секретаренә, кагыйдә буларак, административ комиссия утырышы көненә кадәр 1 эш көне кала хәбәр итәргә тиешләр.

3.6. Әгәр административ комиссия утырышында билгеләнгән санындагы административ комиссия әгъзаларының кимендә өчтән икесе катнашса, ул тулы хокуклы була.

3.7. Административ хокук бозу турындагы эш буенча карар, билгеләмә утырышта катнашучы административ комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.

## 4. Административ җәза бирү турындагы карарны үтәү

4.1. Административ комиссия тарафыннан чыгарылган карарлар административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе Кодексы нигезендә үтәлә.

4.2. Эшләрне алып баруда катнашучы затларның, башка физик һәм юридик затларның административ комиссия тарафыннан чыгарылган карарларны, билгеләмәләрне һәм күрсәтмәләрне үтәүләрен контрольдә тотуны административ комиссиянең җаваплы секретаре гамәлгә ашыра.

## 5. Административ хокук бозуларны профилактикалау

5.1. Административ хокук бозуларны кисәтү максатларында административ комиссия үз эшчәнлеген эчке эшләр органнары, федераль суд приставлары хезмәте идарәсенең территориаль бүлекләре, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы һәм иҗтимагый берләшмәләр белән координацияли.

5.2. Комиссия, рәис тарафыннан расланган график нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә урнашкан авыл җирлекләрендә күчмә утырышлар үткәрә.

5.3. Комиссия үз эшчәнлеген массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы халкы арасында аңлату эшләре алып бару юлы белән профилактик эш алып бара.